# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"1996 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

"1996 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 статья. 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын чыгымнар буенча - 7751735 млн.сум һәм керемнәр буенча 6170727 млн.сум дип расларга.

1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 1581008 млн.сум яки Татарстан Республикасының 1996 ел республика бюджеты чыгымнарының 20 проценты күләмендә билгеләргә".

2 статья. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3 статья. 1996 елда җир өчен салым күләмен исәпләгәндә, 1995 елда гамәлдә булган ставкаларга түбәндәге арттыру коэффициентларын кулланырга:

торак пунктлардан читтә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләре өчен - 2,2;

шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы бистәләр (поселоклар) җирләре өчен - 1,5;

бакчачылык ширкәтләре, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, торак фонды, шәхси гаражлар һәм авыл җирләрендә урнашкан дача кишәрлекләре биләгән җирләр өчен - 3,0;

шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы бистәләрдән (поселоклардан) читтә урнашкан сәнәгать (җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәсендә бозылган территорияләр һәм карьерларны да кертеп), элемтә, транспорт, телевидение, радиотапшырулар җирләре өчен - 15".

3 статья. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. Керемнәргә салымнар буенча түбәндәге ставкаларны билгеләргә:

а) дивидендлардан, акцияләр, облигацияләр, предприятиеләрнең һәм оешмаларның гамәлгә кертелгән башка кыйммәтле кәгазьләре буенча алынган процентлардан (дәүләт облигацияләре һәм дәүләтнең башка кыйммәтле кәгазьләре буенча алынган керемнәрдән тыш) - 15 процент күләмендә; ә кредит оешмаларының шундый ук керемнәреннән - 18 процент күләмендә;

б) видеосалоннардан (видеокүрсәтүләрдән), файдалануга видео- һәм аудиокассеталар биреп торудан, шулай ук аларга яздырулардан - 70 процент күләмендә;

в) казинолардан, уен йортларыннан (урыннарыннан) һәм башка уен бизнесыннан - 90 процент күләмендә".

**4 статья.** 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. Предприятиеләр һәм оешмалар мөлкәтенә салым ставкасын - 1996 елның I кварталына салым салынучы тиешле ба-

заның 3 проценты, 1996 елның П-IY кварталларына 2 процент күләмендә билгеләргә, моңа "АлАЗ" җитештерү берләшмәсе, оборона комплексы һәм җиңел сәнәгать предприятиеләре керми.

"АлАЗ" җитештерү берләшмәсенә ( 1996 елга) мөлкәткә салым ставкасын - салым салынучы базаның 0,1 проценты, оборона комплексы һәм җиңел сәнәгать предприятиеләренә ( 1996 елның П-Ш кварталларына) 0,5 процент күләмендә билгеләргә.

1996 елга физик затлар мөлкәтенә салым ставкасын төзелешләрнең, биналарның, корылмаларның инвентаризация хакының 0,1 проценты күләмендә билгеләргә".

5 статья. 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда исәпкә алырга:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Предприятиеләр һәм оешмалар табышына (кеременә) салым | 1074401 |
| Физик затлардан керем салымы | 196289 |
| Өстәлгән бәяләргә салым | 1736000 |
| Акцизлар | 1113696 |
| Табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләр | 245880 |
| Җир өчен түләү | 81724 |
| Башка төр салымнар, җыемнар һәм башка кертемнәр | 270208 |

72

| | |
|---|---|
| Мәлкәткә салым | 249529 |
| Дәүләт пошлинасы | 7700 |
| Халык хуҗалыгының мөһим тармакларына ярдәм итү өчен предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан алына торган махсус салым | 23000 |
| Хосусыйлаштырудан кергән керемнәр | 29300 |
| Татарстан Республикасының кыска вакытка исәпләнгән республика облигацияләрен гамәлгә ашырудан кергән керемнәр | 383000 |
| 1995 елда кире кайтару шарты белән бүлеп бирелгән акчалар килере | 746000 |
| Кыйммәтле кәгазьләр белән кылынучы гамәлләргә салым | 14000". |

6 статья. 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"14 статья. 1996 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслауга ассигнованиеләр күләменең гомуми суммасын - 6578735 млн.сум; капитал салуларны да кертеп, үсеш бюджетын финанслауга 1173000млн.сум дип билгеләргә".

7 статья. 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"15 статья. 1996 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 7751735 млн.сум күләмендәге ассигнованиеләрне түбәндәге максатларга тотарга:

73

(млн.сумнарда)

| | Барлыгы | шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | агымдагы чыгымнар бюджеты | үсеш бюджеты |
| 1. Дәүләт идарәсе | 125500 | 125500 | |
| 2. Фән һәм архив учреждениеләре | 20450 | 19650 | 800 |
| 3. Сәнәгать, энергетика һәм төзелеш | | | |
| - "Таттөзелешгазлаштыру" дәүләт җитештерү предприятиесе | 45000 | 45000 | |
| - ягулык сәнәгате | 2320 | 2320 | |
| - торак-төзелеш комплексы өчен торак йортлар төзү хакының артуын компенсацияләү | 1500 | | 1500 |
| - капитал салулар | 519000 | | 519000 |
| - проектлау эшләре | 300 | | 300 |
| 4. Авыл хуҗалыгы | | | |
| - авыл хуҗалыгы җитештерүе, шул исәптән: | 1449424 | 1029924 | 419500 |
| җирләрне тамырдан яхшырту | 186000 | 186000 | |
| - минераль ашламалар бәяләренең аермасын каплау | 483000 | 483000 | |

74

| | | | |
|---|---|---|---|
| - катнашазыклар сатып алу өчен компенсация | 209000 | 209000 | |
| - эшкәртү сәнәгате предприятиеләре төзү һәм үзгәртеп кору | 317450 | | 317450 |
| - авылны җәмгыяви үзгәртеп кору объектларын төзү | 102050 | | 102050 |
| - нәсел яхшырту эшләренә, ясалма орлыкландыру һәм элиталы орлыкчылыкка ярдәм | 91000 | 91000 | |
| - лизинг фонды | 32400 | 32400 | |
| - тапшырылган терлекчелек продукциясенә дотация | 450000 | 450000 | |
| Баш ветеринария идарәсе | 17350 | 13850 | 3500 |
| - җир өчен түләү хисабыннан чыгымнар | 81724 | 81724 | |
| - икмәккә дотация | 47000 | 47000 | |
| Кире кайтару шарты белән бүлеп бирелгән акчалар: | | | |
| - азык-төлек бодае сатып алу өчен | 423000 | 423000 | |
| Республика азык-төлек фондына авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу өчен | 349000 | 349000 | |
| 5. Тирә-як мохитне һәм табигый байлыкларны саклау | | | |

75

| | | | |
|---|---|---|---|
| - урман хуҗалыгы | 72000 | 62000 | 10000 |
| - тирә-як мохитне саклау | 35000 | 7500 | 27500 |
| 6. Транспорт | | | |
| - автомобиль транспорты | 68220 | 42220 | 26000 |
| - һава юлы транспорты | 5700 | 5700 | |
| - тимер юл транспорты | 25200 | 25200 | |
| - су юлы транспорты | 12000 | 12000 | |
| 7. Торак-коммуналь хуҗалык | | | |
| - торак-коммуналь хуҗалык | 48140 | 48140 | |
| - яңа тапшырылучы җәмгыяви-мәдәни өлкә объектларын һәм ведомствога караган торак фондын тоту | 350000 | 350000 | |
| 8. Мәгариф | 218387 | 170387 | 48000 |
| 9. Мәдәният | | | |
| - мәдәният һәм сәнгать | 94616 | 71816 | 22800 |
| - кинематография | 18285 | 18285 | |
| 10. "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республика Законын гамәлгә ашыру гамәлләре | 5280 | 5280 | |
| 11. Массакүләм мәгълүмат чаралары | | | |

76

| | | | |
|---|---|---|---|
| - телевидение һәм радиотапшырулар | 26300 | 23500 | 2800 |
| - көндәлек матбугат һәм нәшриятлар | 34596 | 34596 | |
| 12. Сәламәтлек саклау һәм физик тәрбия | | | |
| - сәламәтлек саклау | 453000 | 371100 | 81900 |
| - Санитария-эпидемиология күзәтүе дәүләт комитеты | 62800 | 57500 | 5300 |
| - физик тәрбия һәм спорт | 16550 | 16550 | |
| 13. Җәмгыяви сәясәт | | | |
| җәмгыяви тәэминат учреждениеләре | 52703 | 50803 | 1900 |
| яшьләр сәясәте | 9098 | 6898 | 2200 |
| җәмгыяви яклау гамәлләре | 219000 | 219000 | |
| 14. Башка чыгымнар | | | |
| Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фонды | 53954 | 53954 | |
| - республиканың кыска вакытка исәпләнгән облигацияләрен каплау | 341000 | 341000 | |
| - төрле чыгымнар | 606915 | 606915 | |
| - түбәнгәрәк бюджетларга дотация | 1241423 | 1241423 | |
| Бәяләр индексын фаразлау юлы белән билгеләүгә һәм 1995 елдан күчкән бурычны каплауга бәйле резерв | 150000 | 150000". | |

 

8 статья. 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"24 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кирәк очракларда өстәлгән бәяләргә салым, акцизлар, предприятиеләр һәм оешмалар табышына салым, предприятиеләрнең Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелергә тиешле мөлкәткә салымнар буенча ташламалар бирүне рөхсәт итәргә, бу турыда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясендә квартал саен мәгълүмат биреп торылырга тиеш".

9 статья. "1996 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге эчтәлекле 25 статья өстәргә:

"25 статья. 1996 елда Татарстан Республикасының "Дәүләт хезмәте турында"гы Законының 13 статьясындагы 3 пунктның чираттагы ял итү урынына бару һәм аннан кайту бәясен түләү өлешендәге; 13 статьясындагы 4 пунктның дәүләт хезмәткәрен һәм аның гаилә әгъзаларын дәвалаган өчен чыгымнарны каплау өлешендәге, 13 статьясының 8,11 пунктлары, 15, 16, 23 статьяларының гамәлдә булуы белән бәйле чыгымнар финансланмый, дип билгеләргә, моңа элек кабул ителгән законнар нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен түләү шартлары буенча тотылган чыгымнар керми".

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 8 июле
N 684

3/ 2141806c.txt